СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан,
Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы,
ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б.,
Г.Закиров урамы, 52 йорт

84362) 2-31-44, Саба муниципаль районы факсы (84362) 2-31-74, Саба муниципаль районы башлыгы: tatar.ru, www.sby.tatarstan.ru

№ 58 от 25.02.2026
№________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябреннән №272 номерлы карары белән расланган белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

2022 елның 01 апреленнән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №90-ФЗ Федераль закон, 2023 елның 10 июленнән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №286-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 декабрендәге 272 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 6 нчы пунктның в) пунктчасында «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

2.2. 13 нче пунктта «, акцияләренең» сүзен төшереп калдырырга, «оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар» сүзләреннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

1.3. 16 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яисә уз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яисә мондый белешмәләр бирү мәҗбүри булган очракта, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү хокук бозу булып тора, аларны алмаштырыла торган вазифаларыннан азат итүгә, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртиптә эштән азат итүгә китерә.».

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләүгә һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 декабрендәге 271 һәм 14.11.2014 елгы 272 номерлы карарлары белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2025 елның 11 декабрендәге 27 номерлы карарын үз көчләрен югалткан дип танырга.

**5.** Әлеге карарны рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Миңнеханов